# Гомәр Дашкин һәм аның шигъри иҗаты

I

Пенза ягы — элек-электән үк татарлар Ватаны. Заманында ул күпгасырлык төрки-татар дәүләтчелек тарихында мөһим урын тоткан, Хәзәр каганлыгының, Болгар ханлыгының, Дәшти-Кыпчакның әһәмиятле җирләреннән саналган. Алтын Урда чорында исә хәзерге Пенза әтрафлары бу кодрәтле мәмләкәтнең мөһим мәркәзи төбәкләренең берсе була. Сарай шәһәрендә 1303 елда төзелгән коман (кыпчак, татар)-фарсы-латин сүзлеген-дәге лексик материалларның төп өлеше хәзерге Пенза, Мордовия тарафларында яшәүче мишәр-татарларның телендә саклануы үзе генә дә күп нәрсә хакында сөйли. Бу яклардагы Наручат (Наровчат) шәһәре Үзбәк хан вакытында (1312—1341 елларда идарә итә) Алтын Урда башкаласы вазыйфасын да үтәп ала. Андагы ташпулатлар, мәһабәт мәчетләр чит ил сәяхәтчеләрен дә сокландырырлык була. Франциска һәм Доминика Пицигани төзегән географик картада (1367) хәзерге Пенза тарафларында латинча «Котоба» дип исемләнгән шәһәр дә теркәлгән. Кайбер галимнәр фикеренчә, бу кала Алтын Урда чорының мәшһүр шагыйре Котбның кече ватаны дип исәпләнә. Бу авторның атаклы «Хөсрәү вә Ширин» дастанында (1342) бу җирлеккә хас сүз-шәкелләр теркәлеп калган. XV—XVI гасырларда бу төбәкләр Казан, Әстерхан калалары белән тыгыз икътисади, мәдәни, этник бәйләнешләрдә тора. Татар мәмләкәтләре Мәскәү тарафыннан бетерелгәч, Пенза, Мордовия якларындагы милләттәшләребез колониаль изелү, урыслаштыру сәясәтенә дучар ителәләр. Әмма, күп югалтуларга да карамастан, аларның зур өлеше үзләренең милли аңын, телен, динен, гореф-гадәтләрен саклый, зур татар дөньясының мөһим бер кыйсеме булып кала килә. Бу төбәктән Муса Акъегетзадә (1864—1923), Заһир Бигиев (1870—1902), Гафур Коләхмәтов (1881—1918), Гадел Кутуй (1903—1945), Кәрим Тинчурин (1887—1938), Әдһәм Тенишев (1921—2004) һәм башка бик күп күренекле зыялыларыбызның чыгуы мәгълүм. XX йөздә биредә татар мәктәп-мәдрәсәләре эшли, татарча гәҗитләр, китаплар бастырыла.

Пенза төбәге шәхсән без фәкыйрегез өчен аеруча истәлекле. Мин биредә хәзер ярты гасырга җиткән мөгаллимлек эшчәнлегемне башладым: 1962—1963 уку елында Белинский районы Качкару (Кутеевка) мәктәбендә балалар укыттым.

Пенза тарафларында зур-зур татар авыллары бар. Шуларның иң күренеклесе һәм татар дөньясында иң зурысы — Урта Әләзән (Городище районы). Ул электән үк татарның милли, дини, мәгърифәти үзәкләреннән берсе хисаплана, анда хәзер дә мәдрәсә, дистәдән артык мәчет бар. Авылның тарихы да язылган. Пенза өлкәсендәге 100 меңләп татарның уннан бере диярлек биредә гомер кичерә.

Урта Әләзән, иң беренче чиратта, үзенең тырыш, уңган, булган кешеләре белән мәшһүр. Шундыйларның берсе — Гомәр (үзләренчә, «мишәрчәләп» әйтсәң — Үмәр) Билал угылы Дашкин. Бу — тарихта билгеле атама. Акчурин, Тенишев, Бибарсов, Еникеев, Яушев һәм башка күренекле фамилияләр кебек, Дашкиннар нәселе дә Темников, Арзамас төбәкләрендәге йомышлы татарлар, князь-морзалар катламына барып тоташа. Чыганакларда бу нәсел шәҗәрәсенең башы итеп 1611 елда вафат булган «Дашка Худяк (Дамат)» күрсәтелә. Д. Пожарскийның 1612 елның 7 августында бирелгән грамотасында Дашка һәм аның улы Сүнчәләй (Сюнчелей) князь, ә башка ике улы (Ишмәкәй, Алмакай) морза дип аталган. Петр Беренченең чукынмаган татар морзаларын христианлаштыру турындагы 1713 елгы Указыннан соң, Дашкиннарның бер тармагы чукынып, әкренләп урыслашып китә. Алар арасыннан күренекле шәхесләр дә чыга. Мәсәлән, Константин Сергеевич Дашкин (1858 елда туган) 1911 елда генерал-лейтенант дәрәҗәсен алуга ирешә, күп төрле рәсми бүләкләргә ия була. Дашкиннарның чукынмый калганнары төрле җирләргә, шул исәптән Пенза тирәләренә дә тарала. Боларның да кайберләре морза, дворян дәрәҗәләрен я саклап кала, я кабат алуга ирешә. Гомәрнең әтисе Билал (1870—1930) Дашкиннарның Ишмәкәй...—Мостафа (1742—1819), Сөләйман (1767—1837) тармагы аркылы килүче нәселдән. Ул мәдрәсәдә белем ала, үзе дә шунда татар һәм

гарәп телләрен укыта, дин сабаклары да бирә. Гомәр үз хезмәте белән көн күрүче, шактый укымышлы гаиләдә бишенче бала булып дөньяга килә. Аның туу вакыты рәсми документларда «1912 елның 7 июле» дип күрсәтелә. Ә автор үзе исә дөньяга килү вакытын «1911 ел» дип хисаплый [«Туган елым унберенче егерменче» йөз елда» (гасырда. —Г.Д.)]. Гомәр кечкенә чактан ук укуга һәвәс була, әтисеннән күп нәрсәгә, шул исәптән гарәп, фарсы телләренә өйрәнә. Туган авылында әүвәл мәдрәсәдә, аннан мәктәптә укый. Бер шигырендә «остазыннан» «Һәфтияке фәза» (ягъни Коръәннең җидедән бер өлешен) өйрәнүен дә телгә ала. Гомумән, ул укуда тырышлыгы белән аерылып тора.

Гомәр Дашкин, бер еллап Пенза заводларының берсендә эшләгәч, 1927 елда бер төркем якташлары белән Донбасска китә. Шахтада эшләү белән бергә, рабфакта укыта да. Әтисе үлгәч (15.03.1931), 1930 елда туган авылына кайта. Шул ук елны авылдашы Зәйнәп Алим кызы Мамлиева белән гаилә корып җибәрә. Аларның тугыз баласы була. Болардан кайберләре (Сәгадәт — 1933 елгы; Сәгыйд — 1937 елгы; Җәгъфәр — 1941 елгы; Рифгать) сабый вакытта ук дөнья куя. Калганнары үсеп, тормышта үз урыннарын таба, халыкка, илгә хезмәт итә. Мәсәлән, 1945 елда (әтисе язуынча — 1946) дөньяга килгән Асият Казан медицина институты һәм ординатурасын тәгәлләп, Республикабызның сәламәтлек саклау системасында табиб (пульмонолог) һәм Яңа бистәдәге поликлиникада баш врач булып эшләде. Аннан Пензага кайтып үз профессиясе буенча хезмәт кылуын дәвам итте. Асият Дашкин югары дәрәҗәле белгеч кенә түгел, ә милли җанлы, зыялы зат та. Казанда вакытта ул мәдәни тормышның үзәгендә кайнады. Татар зыялылары арасында дуслары, танышлары күп иде. Аның хакында «Социалистик Татарстан» гәҗитендә Габделбәр Ризвановның «Дустым Асият» исемле күләмле язмасы чыгуын да хәтерлим. Пензага кайткач та бу абруйлы табиб һәм сәләтле шәхес иҗтимагый, милли, мәдәни тормышның үзәгендә кайнады. Хәзер дә ул игелекле эшчәнлеген дәвам иттерә. Гомумән, Гомәр аганың балалары, нигездә, кешеләрнең сәламәтлеген саклау шөгылен

үзләренең профессиясе итәләр: икенче бер улы Зөфәр — табиб, кызлары Сәгадәт (1948 елда туганы), Сания акушерка, шәфкать туташы булып эшли.

Донбасстан кайтып авылда кабат яши башлагач, Гомәр Дашкин иген дә игә, маллар да асрый, йортлар да сала, хисапчы, кибетче дә булып эшли. Үзенең эш-шөгыльләрен ул шигырьләрендә дә телгә ала:

...Эшләдем, чәчтем, сукаладым, тракторлар белән,

Күп көрәштем авырлыклар, юклык, ачлыклар белән.

Бригадир булып та тагын ничә еллар эшләдем...

Авыр җәрәхәт алып, 1938 — 1939 елларда урын өстендә дә ята. Армиягә алынмаса да, сугыш чорының бөтен кыенлыкларын күрә. Нахакка гаепләнеп, хәтта ярты еллап Воронеж төрмәсендә дә утырып чыга. Гомәр ага колхозга да 50 нче елларда гына керә. Бу да аңа рәсми хакимиятнең кырынрак каравына китерә. Ул эчми, тартмый, «биш вакыт» намазын укый, гадел, намуслы тормыш алып бара. Әхлаксызлыкка, эчүчелеккә һәрчак каршы була. Динне, мәчетләрне яклап, күп мәртәбәләр партия Үзәк Комитетына, СССР Верховный Советы президиумына хатлар яза. Моның өчен җирле хакимият тарафыннан штрафларга, төрле кисәтү-куркытуларга дучар була. Әмма бу фидакарь һәм игелекле зат туктап калмый: үз мәсләгенә, кыйбласына һәрчак тугрылык саклый.

...Беркайчан да баш имәдем, кечерәймәдем көн-төштә дә,

Чигенмәдем, алга бардым авырлыклар төшсә дә.

Бу юллар хыял җимеше генә түгел, ә автор табигатенең реаль чагылышы да. Гомумән, Гомәр ага сәләтле, күпкырлы шәхес була. Аның фотография, медицина, бакчачылык белән шөгыльләнүен авыл кешеләре хәзер дә легенда-риваять итеп сөйли. Ул авылда беренче булып 1954 елда ук телевизор сатып ала, башкаларга да аларны көйләшә, ватылган вакытта төзәтеп тә бирә.

Гомәр ага, югары уку йортларында белем алмаса да, үзлегеннән укып, күп тармаклардан белем-мәгълүмат туплый. Указлы мулла булмаса да, еш кына мәҗлесләрдә, мәчеттә вәгазьләр укый, авылдашларына, якыннарына

Коръән серләрен, дини йолаларны аңлата. Авылдагы мәртәбәле аксакалларның берсе, күпләгән оныкларының (17) һәм аларның балаларының (25) хөрмәтле бабасы Гомәр  Билал углы Дашкин 1988 елның февраль аенда мәңгелек йортка күчеп китә. Кабере — Урта Әләзән зыяратында.

Гомәр Дашкин, башка тармакларда шөгыльләнү белән бергә, язу-сызуга, әдәби иҗатка да вакыт тапкан. Әмма ул аларны бастырмаган, үзе өчен, күңел ихтыяҗы өчен язган. Аның иҗат җимешләре белән якыннары, чагыштырмача тар даирә генә таныш булган. Мөгаен, Билал угылы шигырьләр язу белән бала,үсмер чакта ук шөгыльләнә башлагандыр. Улы Асият искәртүенчә, этисе бу эшкә 15—16 яшьләрдә керешә. Күп кенә безгә билгеле шигырьләренең ахырына язылу вакытлары куелган. Аларга карап фикер йөртсәң, Г. Дашкин 30 нчы еллардан алып үлеменә кадәр, ягъни ярты гасыр буена әдәби иҗаттан аерылмаган.

Язамын мин, язамын мин, язамын,
Әдип булып язарга яратамын, —

ди ул бер шигырендә. Мөгаен, бу еллар аның яшәү асылын да чагылдырадыр.

Мин Асият Дашкинны аның Казанда эшләү чорыннан, ягъни 70 нче еллардан бирле беләм. Сирәк-мирәк булса да, аралашып, хәбәрләшеп торабыз. Узган ел ул этисенең шәхси архивындагы бер өлеш материалларны, иң беренче чиратта шигырьләрен, Казанга алып килде дә, аларны карап, бәяләп, мөмкин булган кадәрен гарәп графикасыннан хәзерге язуга күчереп бирүне үтенде. Ул архивтагы язмалар берничә дәфтәргә теркәлгән (бер өлеше оригиналда, икенче өлеше — фотокүчермәдә). Мәгълүм ки, башка авыллардагы кебек, Урта Әләзәндә дә янгыннар еш булып тора. Аларның кайберләре Гомәр Билал угылы архивында да теркәлеп калган. Мәсәлән, автор «Утыз икенче ел кергәч Иляһи бер бәла салды, Бар милкемдәге хәзинәм(не), жаль, Раббым хозурына алды», — дип яза. Шушы ук шигырьдә 1933 нче елның «баш июнендә «бер сәгатьтә» авылның «ике йөз өе янды» диелгән мәгълүмат та бар. Асият Дашкин әйтүенчә, мондый «пожарлар» вакытында этисенең күп кенә язмалары янып юкка чыга.

Гомәр Дашкин архивының миңа билгеле өлешендә, әдәби әсәрләрдән тыш,  узган гасырның 30—80 елларда теркәлгән башка төр язмалар да бар (алар барысы да диярлек гарәп язуында). Болар арасында  «Коръән»нән өзекләр, гарәп һәм татар телләрендә дини  вәгазь текстлары, ислам йолаларын (корбан чалу, ураза тоту...) аңлаткан язмалар, аерым нәсел шәҗәрәләрен, балаларының, туганнарының туган, яшәү вакытын чагылдырган белешмә-мәгълүматлар да бар. «Татар тарихы» дип исемләнгән берничә битлек текстта мәктәп дәреслекләренә, төрле китапларга нигезләнеп, халкыбыз тарихы бәян ителә. Анда Чыңгыз һәм Батый ханнар, Аксак Тимер (Тамерлан), Туктамыш, Иван III һәм Иван IVчеләр хакында мәгълүматлар теркәлгән. Автор үзен татарның бер вәкиле буларак тоя, аның дәүләтчелектән, мөстәкыйльлектән мәхрүм ителүен үкенү аһәңендә белдерә.

Г. Дашкин язмаларында җирле төбәк тарихына мөнәсәбәтле мәгълүматлар да бар. Хәзерге Пенза тарафларында ул элек болгарлар, бортаслар, мукшылар яшәвен искәртә. Алтын Урда чорында биредә шәһәрләр булуын (Наручат, Мухшы һ.б.), аларда мәчетләр, ташпулатлар корылуын да әйтеп китә. Шәхси архивтагы бер өлеш материалларда XVII—XX йөзләргә кагылышлы тарихи, икътисади, дини-мәдәни факт-мәгълүматлар теркәлгән. Автор фикеренчә, Әләзән XVII—XVIII гасырларда ныклап үсеп китә. Аның бер өлеш халкы Арзамас, Алапаев якларыннан XVII йөзләрдә үк бирегә күчеп килә. Үзенең туган авылында ул 1900 елларда 550, 1935 елда 1012, 1947 елда 850  хуҗалык булуын әйтә. Ватан сугышында 350 әләзәнле катнаша, күпчелеге төрле бүләкләргә ия була.

Г. Дашкин язмаларында авыл тормышындагы аерым вакыйгалар, мәчет-мәхәлләләр һәм имамнар хакында белешмәләр, якташларының эш-шөгыльләре (иген игү, мал асрау, һөнәрчелек...) хакында да фикерләр әйтелгән. Хәтта «Себергә, каторгага сөрелүчеләрнең» дә кайберләре телгә алына. Юкарак кына бер дәфтәрдә « Йокы һәм төш күрү» темасы яктыртыла. Шәхси эчтәлектәге берничә хат та бар.

Г. Дашкин архивындагы бу төр язмаларны  һәм әдәби әсәрләрне күздән

кичергәч, бу затның шактый белемле, мәгълүматлы, күзәтүчән, кызыксынучан кеше булуына янә бер мәртәбә ышанасың. Язма теле дә ярыйсы гына. Нигездә, ул XX йөз башы татар әдәби теле традицияләренә таянып эш итә. Гарәп, фарсы, төрки сүзләрен дә белеп, урынлы куллана. Шуның белән бергә, Г. Дашкин язмаларында сөйләм теленә, аеруча шул тараф шивә-диалектына хас сүзләр һәм шәкелләр, урыс теле алынмалары да күзгә ташлана.

II

Г. Дашкинның минем кулдагы язмаларының төп өлешен шигъри текстлар алып тора. Алдан ук шунысын да искәртик: бу зат профессиональ шагыйрь түгел, әйткәнебезчә, аның парчалары, минем белүемчә, басылмаган да, тәнкыйди иләктән үткәрелеп тикшерелмәгән дә. Алар, кыскарту-үзгәртүләргә дучар булмыйча, башкалар тарафыннан редакцияләнмичә, ничек язылган, шулай сакланган. Бу хосусиятләре белән аның шигырьләре нәшер ителгән язмалардан теге яки бу дәрәҗәдә аерылып та тора. Чөнки алар як-якка каранмыйча, цензура, рәсми мөхәррир киртәләрен уйламыйча, иҗат ирегенә, күңел ихтыяҗларына тугры калып язылганнар. Бу сыйфатлары белән «пензяк» шагыйренең парчалары мөһаҗир татарларның, җөмләдән Финляндиядә яшәп иҗат иткән Хәсән Хәмидулланың (1900—1988) әсәрләренә дә охшап китә.

Гомәр Дашкин шигырьләре, гәрчә аларда объектив һәм субъектив характердагы аерым җитешсезлекләр (рифма һәм ритм төгәлсезлекләре, тел-стиль кытыршылыклары, фикри буталчыклыклар, кабатланулар...) булса да, гомумән алып караганда, алар укучылар, әдәбият тарихын өйрәнүчеләр, рухи мирас белән кызыксынучылар өчен билгеле бер әһәмияткә ия. Шулай ук бу парчалар үткән тормышны, шул чор кешеләренең, шул исәптән авторның да рухи халәтен, шатлык-кайгыларын, мәшһүр Әләзән төбәгендә яшәүчеләрнең тереклеген, гореф-гадәтләрен, телен танып-белү ягыннан да дикъкатькә лаек.

Гомәр Дашкин шигырьләренә нинди сыйфатлар хас соң? Хәзер аларның кайберләренә кыскача гына тукталып китик.

«Пензяк» шагыйренең әсәрләре идея-тематик яктан шактый бай. Аны инсан рухының, кеше яшәешенең, милләтнең, илнең, җәмгыятьнең төрле мәсьләләре, факт-күренешләре борчый; автор алар хакындагы уй-кичерешләрен, эмоциональ һәм фикри бәя-мөнәсәбәтләрен шигъри юлларда белдерергә омтыла.

Мәгълүм ки, совет чоры басма әдәбиятында XX йөз башы сүз сәнгатенә хас булган милли мотивлар чагыштырмача кими һәм хәтта югала да бара. Г. Дашкин шигырьләрендә исә татар тематикасы, милли хәят шактый зур урынны били. 1934 елда иҗат ителгән «Ярлылык(ның) башы нәрсәдә» шигырендә автор, мәгърифәтчелек рухында, «Милләтемез тора калып, Алга илтүче юк алып», «Кызганыч милли хәлемез», — дип искәртә, гафләт йокысыннан уяныргa чакыра. «Аңла, татар» исемле парчасында (ул сугыштан соңгы елларда язылган булса кирәк) шагыйрь милләт язмышын аның газиз теле белән тыгыз бәйләнештә карый; милли тәрәккыяткә иман-ышанычын белдерә.

Әй татар, булдыклы татар, килмәсен сезгә хәтәр,
Юкмы арагызда дошман — булса ул сезне сатар.

Иң җитешкән өлге — инсан — хәятыңны беләсең,
Кызганыч, телен югалта, татар була керәшен.

Татар теле — кыйммәтле тел, дөньяда юк мисле аның,
Тел күтәрә иң югары тәхетенә дөньяның...

Юк, синең яшерен татардан гади халыктан сере(ң),
Син, татар, сөй үз телеңне мәрҗан кеби һәр бере.

Бабаларымыз изелгән, булып замана коллары,
Әле безгә бу көн ачык теләсәң күк юллары.

Социализм чорында, бигрәк тә 30 нчы еллардан башлап илдә дингә каршы көрәш чын мәгънәсендә көчәя. Басма сүз сәнгатендә ул аеруча калку гәүдәләнә. Г. Дашкин — дини, милли тәрбия алган зат. Бу сыйфатларына ул һәрчак тугры кала. Анда хәтта атеизм котырган елларда да дингә тел-теш тидерү юк. Киресенчә, автор Алланы зурларга, үз тереклегеңне ислам кануннары нигезендә алып барырга чакыра. Аның «Дога» шигыре чын мәгънәсендә Тәңрегә хөрмәт, ялвару, аннан рәхим-шәфкать көтү рухы белән сугарылган. 8 строфалык бу парчаның һәрберсендә «Иляһи» сүзе телгә алына, аңа мөрәҗәгать ителә:

Йа Иляһи, кул күтәреп нечкә күңел, яшь белән,
Каршыңа килдек, Йарабби, рәхмәтең теләп синдән.

...Йа Иляһи, бу галәмдә хәлләремез аяныч,
Сач гыйбрәт илһамыңны синдә генә таяныч...

Шагыйрь фикеренчә, динсезлек, имансызлык һәр төрле әхлаксыз эш-гамәлләргә китерә. Авторны аеруча совет чорында киң колач алган хәмер эчү, зина кылу кебек күренешләр борчый. «Шәйатыйн (шайтаннар) кемнәрне үзенә ияртә» шигырендә ул җиһанны «исереклек туе», «аракы, зина, усал сүз» каплап алган,— ди. Мондый хәлдән котылуда шагыйрь Алладан ярдәм сорый. Автор күзаллавында дини һәм милли барлык бер-берсе белән тыгыз бәйләнешле:

Укы намаз, шаулап азан.
Яңгырасын милли яган.

Белем-мәгърифәтне зурлау, матур әхлакый сыйфатларны мактау, аларның капма-каршылыларын тәнкыйтьләү татар сүз сәнгатендә элек-электән күзәтелә. Г. Дашкин да бу төр традицияләрне дәвам иттерә. Аның карашынча, белем — чын «дус», «тормыш бирүче», «шатлык» китерүче, «наданлык» исә «ярлылык җимешен» бирүче, бер «егач тик». Мәктәп — балага белем-тәрбия бирүнең төп учагы. Әмма әле ул, шагыйрь уйлавынча, үз вазыйфаларын тиешенчә үтәми. Хәзерлексез, тупас, исерек мөгаллимнәр,

ришвәтчелек укучыларга тискәре йогынты ясый,— алар бозыла, шуның нәтиҗәсендә җәмгыятьтә исереклек, зина кылу, караклык кебек күренешләр киң тарала. Бүгенге тормышта да күзәтелә торган «диплом сатып алу»га да авторның карашы тискәре:

Сатып алган диплом, аңла, наданлыкка ишарә,

Укып надан калдырган учительләргә ләгънәт, нәләт (1977 ел).

Шагыйрь үз укучыларын гадел, намуслы, шәфкатьле, бер-берсенә дус булырга өнди:

...Усаллыкны читкә ташла,

Кара эчеңне кыл ап-ак

*        *        *

Иптәшкәем, бир кулыңны, яңадан дуст булаек,

Дошманлыкны кырып түгеп, дустлык белән тораек.

Дустларым меңләп булса да, һаман тырышам көн дә,

Дустларым артсын диеп көндә, дошман калмасын кем дә...

Теләсә нинди чор, кыйтга, ил, халык, җәмгыять яшәешенең нигезен, асылын тәшкил иткән хезмәт хакында гомере буе эш-шөгыльдән аерылмаган Гомәр Билал углы да үз уйлануларын, фикер-кичерешләрен бәян итә. Бер шигырен ул мондый юллар белән башлый:

Яшь идем мин, яшь чагымда иген эшен эшләдем,

Ат, сука, чалгы, урактан башка корал ишетмәдем.

Аерым парчаларында шагыйрь һөнәрсезлекне, ялкаулыкны бәхетсезлекнең, фәкыйрьлекнең, көферлекнең нигезе дә дип карый:

...Һөнәрсез дөньяда ач,

Чын мәгыйшәткә ул мохтаҗ,

Дин гыйлемен белмәгәннән кач,—

Көферлеккә чумма инде.

Гомәр Дашкин аерым тарихи вакыйгаларны, иҗтимагый факт-күренешләрне дә читләтеп үтми. 1943 елның январь башында, ягъни

сугышның иң каты чорында ул үз көндәлегенә мондый парчаны теркәп куя:

Уйнамаска, көлмәскә халык күзе яшьле чакта,
Туганнар дошманга каршы елап сугышкан чакта.

Сугыш сафында үсмерләр унар меңләп үлгәндә,
Кемнәр гаклы бар әйтер шул вакытта көлгәнгә.

Бу юлларда автор ил белән бергә сулаучы, аның кайгы-газапларын үзенеке итеп тоючы ватанпәрвәр, халыкпәрвәр буларак чыгыш ясый. «Тарих» шигырендә Рәчәйдәге ачлык елы (1921 ел күздә тотыла), аның коточкыч афәтләр китерүе рәсемләнә. Парча бик тә аянычлы, үкенечле фикер белән төгәлләнә:

... Каршы елы зур уңышлар бик халыкны шатлаган,
Лик ( ләкин. — Х. М.) халыкның ул бәхеткә яртысы да калмаган.

«Әләзәнлеләрнең киләчәге» әсәрендә Иван Грозныйның татарларны тар-мар итүе, аларның «тәрәкъкыять юлына» төрле «киртәләр салуы», милләттәшләребезне таркатуы, урыс, мордвалар белән катнаштыруы, «урыс нәзарәте астында сәяси кол итәргә» омтылуы гәүдәләндерелә.

Гаилә,— хезмәт кебек үк, кешелек җәмгыятенең һәм инсани тереклек дәвамчанлыгының нигезе, төп буыны. Бу мәңгелек мәсьәлә дә зур гаиләдә туып-үскән, үзе дә дистәләгән баланың, күпләгән оныкларының атасы, бабасы булган Г. Дашкин шигырьләрендә чагылыш таба. Бер парчасында ул әткәй-әнкәйләр булуны, хатының («иптәш») белән гомер кичерүне «табигый бәхет» дип саный, буыннар дәвамчанлыгын «алмагач»ның алма бирүе белән чагыштыра. Шагыйрьнең «сөекле балалары» Сәгыйд белән Рифатка багышлап язылган мәдхия-мәрсиясе дә самими хисләр, чын сөю-ярату тойгылары белән сугарылган. Автор аларны үзенең «бәгырь җимеше», «былбылы», «сандугачы», «шадлыгы» дип атый.

...Мин синең һәрбер сүзеңдән мәгънә, гайрәт алып,
Икъбалга (бәхеткә, киләчәккә. — Х. М.) салдым эзләр, гайрәтемдән шатланып.

*      *      *

...Туймадым, күзе нуры,

Туяр кадәр карамадың.

Аһәңлелек шатлыкларыңа

Безне дә туйдырмадың...

Гаугалы гаиләләрне, исерек һәм тугрылыксыз ир-хатыннарны, ата-анасы була торып та ятимлек язмышына дучар ителгән балаларны күреп шагыйрьнең йөрәге телгәләнә. Шундыйларның берсе исеменнән язылган әсәрдә мондый әрнүле юллар бар:

Кем мин, нинди аталамын, мин бит юктан килмәгән,

Атасыз-анасыз диеп әйтмәсен кем белмәгән.

Әтием эчкегә баткан, әнием Мәскәүгә качкан,

Исереккә әнием үзе үләнүгә (өйләнүгә. — Х. М.) юл ачкан...

...Әтием эзли хатын тикшереп ил марҗасын,

Прокатка түләп бетерә нибар тапкан акчасын...

Бу хәлне кәгазьгә теркәгәннән соң, автор үз исеменнән мондый нәтиҗә ясый:

...Күпчелекнең гомре үтә, сөешергә кемнедер көтә-көтә,

Туза үзе, бәхте кача, картлык белән үлем җитә.

Күп кенә башка каләм әһелләре кебек, Г. Дашкин да туган авылы хакында үзенең фикер-кичерешләрен бәян итә. Аның 1947 елда язылган «Авыл халкыма» шигыре туган төбәгенә, аның кешеләренә ихтирам, хөрмәт хисләре белән сугарылган. Кече ватанын бәхетле, аңлы, нурлы итәр өчен автор, гәрчә каршы төшүчеләр булса да, бөтен «җанын», «кодрәтен» бирергә әзер:

Сөям сине, Әләзәнем, җан куяр идем сиңа,

Ни сәбәптер каршы төшә күп вакыт халкың миңа.

Аттырыр идем, Әләзәнем, өстләреңә нурлы таң,

Үстереп кояш нурындан башларыңда көчле аң.

Никадәр бар миндә кодрәт, шул кадәрле эш бирәм,

Мин аларга нур чәчеп, бәхет дигән иген бирәм.

Гөлләренә су сибәм, нәфис хуш исләр иснәтәм,

Мәңгелеккә алар өчен мин исле гөлләр үстерәм...

Һәрбер инсан — анабыз Табигатьнең баласы. Бу хакыйкатьне Г. Дашкин да тирәнтен тоя. Аның өчен аеруча кояш якын. «Җир кояшы» шигырендә ул, мәсәлән, табигатьнең бу җисемен, борынгы мифлардагы кебек, изгеләштерә, аны бөтен тереклекнең, матурлыкның чыганагы дип карый:

...Тыгыз болытларны сөзеп, кояш чыгып нурын сибәр,

Мәңгелек бозлар эреп, сулар китеп, җире кибәр...

Шул вакыт гөлләр үсеп, атыр алар матур чәчәк,

Чәчеп алар нәфис исләр бөтен илдә исәчәк...

«Җәйдән файдаланып» парчасында автор «кояш чыгу»ны, «матур язны» мактый да, табигатьнең бер җимеше булган адәм баласына дәшеп, болай ди:

...Хисләреңне уят, тарат,

Җәй нурлары белән агарт.

Тәнең саулык белән җәен,

Гаклың шатлык белән тазарт.

Г. Дашкин, башка күп кенә каләм әһелләре кебек, мәхәббәт темасын да читтә калдырмый. Аның бу төр парчаларында, яшь-җилкенчәккә хас хисләр белән бергә, ир белән хатын мөнәсәбәтләре дә гәүдәләнеш тапкан. Автор мәхәббәткә корылган гаиләви тормышны, балалар үстерүне кеше өчен бәхет, рухи комфорт дип саный.

Г. Дашкинның әдәби мирасында башка темаларга язылган шигырьләр дә бар. Хәтта ул, Ибне Синаның синкретик традицияләрен дәвам итеп, тыйбка (медицинага, дәва-шифага) мөнәсәбәтле фикерләрен дә тезмә юллар

белән белдерә. Мәсәлән, бер парчасында шагыйрь витаминның балалар өчен кирәклеге, аның A, Б, C, D төрләре нәрсәгә файдалы булуы хакында яза:

...Витамин A үстерә, буй-әгъзаларны ныгыта,
Б дигәне ми үстереп, нервларны ныгыта...

Г. Дашкин, олыгая барган саен, яшәү һәм үлем, тереклек мәгънәсе кебек фәлсәфи мәсьәләләр турында күбрәк уйлана башлый. Кайбер парчаларында хәтта ул үзен хыялый рәвештә якты дөньяда гүя «ахыры» көнен уздыручы, китеп баручы рәвешендә күзаллый, табигать, гаиләсе, таныш-белешләре белән бәхилләшә. Үлеменә өч ел кала язылган бер шигырен ул мондый юллар белән башлый:

Көн бетә, күренә килә шәфәкъ таңы да инҗә,
Истә калыр үткән эшләр төштә күренгән тик кенә.

Һәркемнең гомере чикле, үлем котылгысыз. Шуңа күрә һәр инсан Ходай Тәгалә тарафыннан үзенә бирелгән гомерне «тырышып», башкаларга «сүзләре», «эше» белән үрнәк булырлык итеп яшәргә чакыра:

Ил кашында иң сөекле, иң бәхетле шул кеше:
Илдә үрнәк йөрсә аның сүзләре һәм дә эше;

Макталу, изге булып һәркем аны искә алыр,
Күп халык үрнәк алыр, үзләре дә макталыр.

...Тырышлык — бетмәс исем» дип аталган бу шигырь Йосыф Баласагунлы, Сәйф Сараи, Габдулла Тукайлар җырлаган «камил инсан», «игү ат», «гүзәл эз» калдыру мотивларына аваздаш юллар белән төгәлләнә:

...Ул тырышлык аркасында «чын кеше» исмен алыр,
Үзе төзеп мәңгегә тере булып исме калыр.

*       *       *

Г. Дашкин шигырьләренең күпчелеге лирик эчтәлектә. Арада лиро-эпик характердагы язмалар да очрап куя. Шундыйларның берсе — «Сәяхәтем» әсәре. Анда каһарманның хыялында күргән-кичергән хәлләре,

кичерешләре бәян ителә. Сәфәр, төш күрү алымын куллану авторның кайбер башка шигырьләре өчен дә чит түгел. Аерым әсәрләре әңгәмә-диалогка корылган. Мәсәлән, бер язмада ата һәм бала әңгәмәсе аркылы тормыш тәҗрибәсе, әхлакый һәм инсани кыйммәтләр гәүдәләндерелә. Шагыйрь иҗатында робагый (дүртьюллык), фәрд (икеюллык), мәдхия, мәрсия, хат, пейзаж лирикасы, эпиграмма, мөнәҗәт һәм кайбер башка жанрдагы әсәрләр бар. Урыны белән сатирик һәм юмористик табигатьтәге парчалар да, бәет-җырларга тартым, аларга иярү, «стилизация» рәвешендә язылган юллар да күзгә ташлана.

...Тагын җырлыйм бер генә җыр шушы кызга карата,
Татлы ашарга, аз эшләргә, күп йокларга ярата.

...Носовой платокларым: берсе аклы, берсе күк,
Теләгән иптәшем бер син, теләмәгәнем илдә күп...

* * *

Тилегә сез ни барыгыз гаклы юк дип әйтәсез,
Ишетә дә тагын тилерә, гакыл юлын бигәйтәсез.

* * *

... Хурлый башласаң иреңне, аузың күбекләнә,
Котырган эт тик ырлап юк-барын эзләкләнә...

Г. Дашкин шигырьләре, нигездә, икеюллык һәм дүртьюллык строфалар белән язылган. Тәүгеләре аа бб рәвешендә кафияләшкән. Ә дүртьюллык строфаларда рифмалашуның абаб, абвб, аааб һәм башка төрләре күзәтелә. Мәсәлән, «Ярлылык башы нәрсәдә?» шигыре аааб вввб... шәкелендә рифмалашкан. Шигъри үлчәмнәрдә дә төрлелек бар. Күбрәк 15—15, 8—8 иҗекле строфалар өстенлек итә. Арада гаруз, ягъни классик шигырь белән язылган әсәрләр дә шактый. Шигырьләрнең бер өлеше төп эчтәлеккә, мәгънәгә туры килешле атамалар белән исемләнгән. Аерым парчалар хикмәтле сүз әйтүгә, афористик фикерләүгә корылган.

Йокы алмый кешене кайгы керсә эченә,

Борча тешләгән шикелле төн каталап ( төн буенча. — Х. М.) кычына...

* * *

...Табигатьтә һәр бала тик тумаган, юк булмаган,

Тәрбия булмаса, мәгълүм, ул бала кала надан...

Гомәр Дашкин, гәрчә матди тереклекнең исәпсез-хисапсыз эш-мәшәкатьләре белән мәшгуль булса да, гомере буе әдәби иҗатына хыянәт итми, аңа тугры кала. Шигърият язу-сызу аның өчен күңел канәгатьлеге, куаныч-шатлык бирә торган бер дөнья. Бу хакта, мөгаен, авторның үзеннән дә артык әйтеп булмый торгандыр.

Укысам бер язу дөнья иңәм (иңлим. — Х. М.),
Гизәм дөнья, ахирәткә дә тиенәм.

Ниләр килми, ниләр булмый кашымда (каршымда.— Х. М.),
Бары көләм, якты уйлый башым да.

Менәм аена, һава эчендә йөзәм,
Чыдыйм куркынычларга да — түзәм.

Шулар бары күз алдымда, юлымдин,
Чыга алар шигырь булып каләмдин.

Гомәр Дашкин шигъриятә, әлбәттә, югары дәрәҗәләргә ирешә алмаган. Әмма аның бар булган иҗаты ихласи, табигый-тормышчан. Шагыйрьнең теләк-максатлары изге, игелекле: илгә, халыкка хезмәт итү. Аның «Теләк» исемле парчасы (1947) бу хакта ачык сөйли:

Күңлем уйлап,
Телем сөйләп,
Кулым язган
Көйле җөмләләрем
Ил каршында шифа булып
саналсын.

Җаным сөйгән
Ил халкының
Зиһененә
Шигырьләрем
Якты йолдыз булып нур салсын!

* * *

Гомәр Дашкинның күләмле генә язма мирасында идея-сәнгати яктан төрле дәрәҗәдәге шигырьләр бар. Кабатланулар, тупасрак сүз-гыйбарәләр дә очрап куя. Аерым язмалар үтә дә шәхси характерда. Биредә исә без игътибарга лаеклы шигырьләрне сайлап алырга тырыштык. Әйткәнебезчә, Г. Дашкин әсәрләренең барысы да диярлек гарәп хәрефләре белән шул чор орфографиясенә туры китереп язылган. Хәзерге графикага күчергәндә, аларның оригиналда язылыш үзенчәлекләрен өлешчә сакларга тырыштык. Редакцияләү дә хосусый характерда булды. Авторның язу рәвеше (почеркы) урыны белән уку өчен чагыштырмача авыр. Фотокүчермәдә бирелгән аерым текстлар тонык, хәтта кайчак алардагы аерым юлларны укып та булмый. Шул сәбәпле бер графикадан икенчесенә күчергәндә аерым төгәлсезлекләр китүе дә табигый. Мондый җитешсезлекләр өчен укучыдан алдан ук гафу үтенәбез.

Г. Дашкинның «шигъри дәфтәрләре» төрле елларда (нигездә, 30—80 елларда, ягъни әдип гомеренең соңгы ярты гасырында) язылган. Автор үзе аларны, кагыйдә буларак, тематик төркемнәргә, махсус рубрикаларга аерып тормаган. Күпчелек шигырьләренең язылу вакыты күрсәтелгән. Шуңа күрә без аларны, оригиналга тугры калып, нигездә, хронологик принципта урнаштырырга омтылдык. Кыскартулар күп нокталар белән, ә авыр укылган сүзләр сораулар ярдәмендә бирелде. Исемсез шигырьләргә безнең тарафтан куелган атамалар квадрат җәяләр эчендә язылды.

Гомәр Билал угылы Дашкинның тууына 100 ел тулу уңае белән әзерләнгән бу китап шигърият сөючеләрнең, аеруча пензалыларның игътибарын җәлеп итәр дип уйлыйбыз.